**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

29.08.2013 | № 5-17/тэ

Казан ш.

***Кулланучыларга «Жилищно-коммунальные услуги» ҖЧҖ тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә тарифларны билгеләү турында***

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә электр һәм җылылык энергиясенә карата бәя кую турында» 2004 елның 26 февралендәге 109 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (куллану) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифларны һәм бәяләрне исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә кулланучыларга «Жилищно-коммунальные услуги» ҖЧҖ тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә тарифларны билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф карар үз көченә кергән көннән гамәлдә була.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 29.08.2013 № 5-17/тэ карарына кушымта

# Кулланучыларга «Жилищно-коммунальные услуги» ҖЧҖ тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә тариф

| Тәртип саны | Муниципаль берәмлек, җылылык белән тәэмин итүче оешма, кулланучылар категориясе исеме | Җылылык энергиясенә тариф | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кайнар су | басым астында сайланма пар | | | | киcкен һәм редукцияләнгән пар |
| | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Зеленодольск муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «Жилищно-коммунальные услуги» ҖЧҖ* | | | | | | |
| 1.1 | Җылылык энергиясен җитештерү һәм тапшыру өчен түләүче кулланучылар: | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 1965,54 | - | - | - | - | - |

* салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге